

# “Баш иябез Бөек елларга”

# 1941-1945

## Бөек Ватан сугышы елларындагы тыл ветераннары турында Хәтер альбомы

**Югары Шытсу, Түбән Шытсу, Елыш авыллары ветераннары**




**Дәүләтгәрәева (Нургалиева) Наилә Нургали кызы**

Дәүләтгәрәева (Нургалиева) Наилә Нургали кызы 1932 елның 18 февралендә Югары Шытсу авылының Галия һәм Нургали Шәвалиевлар гаиләсендә икенче бала булып дөньяга килә. Абыйсы Шәмсевәли аннан 2 яшькә генә өлкәнрәк була, этисе Нургалиев Нургали Югары Шы тсу авылы колхозы рәисе, әнисе колхозда төрле эшләрдә эшли. Әти-әниләре аерылышу сәбәпле Наилә абыйсы Шәмсевәли белән этиләренең абыйсы – Шәвалиев Хаҗи гаиләсендә тәрбияләнәләр, Наиләгә ул вакытта икенче генә яшь була әле. Башта баланы әбисе карый, ә менә Наилә мәктәптә укый башлагач әби авырый башлый, бу вакытта инде бәләкәй Наиләгә әбисен карау йөкләнә, чөнки өлкәннәр эштә, эшне берничек тә калдырырга ярамый. Мәктәптә Наилә хәрефләрне өйрәнеп, аларны кушып бераз укырга өйрәнә. Үзенең әйтүе буенча: “Уку бик аз эләкте, укытучы Хәбибә апа 4 класска хәтле күчереп барды инде, мин укырга бик сирәк көннәр генә баруга карамастан, чөнки йөрмәвемнең сәбәбен ул яхшы белә иде”.

“Сугыш башлануы бик авыр хәсрәт булып истә калган, елаш, озатышу, Хаҗи абыйның, Бигәнәй авылында яңа гаилә корып яшәүче һәм безнең янга килеп булышып йөрүче этинең сугышка китүе, болай да җиңел булмаган тормышны тагын да авырайтты” – дип искә ала ул вакытларны Наилә әби. Эшкә яраклы бар кеше дә эшли, ә бала-чага өй эшләрен башкара, яшь балаларны, карт әбиләрне карау да алар өстендә була. Ә инде эшче көчләр җитмәгәч, бераз кул арасына керердәй балаларга да эшкә әйтә бригадир. Шулай итеп унбер генә яшьлек Наилә дә колхозның төрле эшләрендә катнаша башлый. “Урак ура идем , ә көлтәне күтәреп куя алмый идем әле, чөнки гәүдәгә дә бәләкәй идем, ач та идек инде ул чакта, шуңа көч тә җитмәгәндер инде”- дип күз яшьләре белән сөйли Наилә әби.

1945 елның 9 мае да бик исендә калган Наилә әбинең. “Сугыш беткән дип хатыннар кычкырыштылар, елаштылар, сөенечтән дә, көенечтән дә инде, чөнки үлеп калучылар да, госпитальләрдә ятучылар да, хәбәрсез югалучылар да бик күп иде шул, кайтырдайларны кайчан кайтырлар икән дип тә чамалап карадылар”- әле үнөч яше генә тулган Наилә дә зурлар рәтендә эшләп йөри һәм алар белән бергә туганнары, абыйсы, әтисе турында уйлый, кайгыра. Бәхетенә, Хаҗи абыйсы да, әтисе дә исән-сау сугыштан әйләнеп кайталар.

Сугыш беткәч тә бик авыр була, Нургалиева Наилә башта төрле эшләрдә, аннары сыер савуда фермада эшли. “Сыер сауганда фермада кунулар, шунда кайчак зур казанда бәрәңге пешереп ашаулар, торак идәннәрен юулар, сыерларга азык җитмәү, аларның күтәрәмгә калулары да, үзебезгә ашарга җитмәүләр дә, барысы да бүгенгедәй күз алдында тора, бик-бик авыр булса да кайчак сагындыра да “ – ди, Наилә әби.

1957 елда Наилә тормышка чыга, Дәүләтгәрәев Фәрхетдин белән гаилә коралар, 5 бала: 4 кыз һәм 1 ул тәрбияләп үстерәләр, барсына да югары белем алырга булышалар. Йортлар җиткерәләр, алмагачлар, яшелчәләр үстерәләр, мал асрыйлар, умарталар үрчетәләр.

Дәүләтгәрәева Наилә Нургали кызы озак еллар пенсиягә чыкканчы сарык караучы булып эшли, эшендә зур уңышларга ирешә. Мәскәүгә ВДНХга чакырып шул уңышлары өчен алтын медаль белән бүләклиләр. Әле пенсиягә чыккач та байтак еллар сарык фермасында эшләвен дәвам итә Наилә апа, эштән туктагач та көзге, язгы кызу эшләр башланганда, үтенечләрен кире какмыйча эшкә йөри ул.

Тыл ветераны Дәүләтгәрәева Наилә Нургали кызы сугыш бетүнең юбилей даталарына багышлап чыгарган барлык медальләре белән дә бүләкләнә: 30 ел, 40 ел, 50 ел....

5 бала тәрбияләп үстергән өчен “Ана даны” медаленә лаек була.

Бүгенге көндә Дәүләтгәрәева Наилә Нургали кызы улы – Дәүләтгәрәев Миннемулла гаиләсендә бәхетле картлык кичерә.



**Галимуллин Тимергали Галимулла улы**

Галимуллин Тимергали Галимулла улы 1932 нче елның 4 нче июлендә Югары Шытсу авылында колхозчы гаиләсендә дөньяга килә. 3 класс Югары Шытсуда, 1 класс Түбән Шытсуда белем ала. 8 яшьтән ат белән тырмада йөри.

Сугышка гаиләдән бер кешесен дә озатмаган булса да, авырлыкны шактый кичерергә туры килә аңа. Ул чорда яшәгән һәркем шикелле баздагы черек бәрәңге, кычыткан белән тукланып җан асрый. “Икмәк ашау төштә генә күргән кебек була иде”,- дип искә ала Тимергали абый.

Сугыш вакытында “Беренче май” колхозында эшли ул. Сугыш беткәннән соң, 1961 елда Нурзия апа белән тормыш кора. Аларның өч балалары туа.

Хәзерге вакытта Нурзия апа бакый дөньяга күчкән. Тимергали абый лаеклы ялда, балалары Гафур абый һәм килене Венера апа белән бергә яшиләр. Оныклары да аларга еш киләләр, Тимергали абыйның һәрвакыт хәлен белеп торалар. Бүгенге көндә Тимергали абый бәхетле картлык кичерә.

Тимергали абыйның шулай ук орден-медальләре дә бар.

Орден:

“60 лет Победы в Великой Отечественной Войне 1941-1945 гг.”

“65 лет Победы в Великой Отечественной Войне 1941-1945 гг.”

Удостоверние һәм орден:

70 лет Победы в Великой Отечественной Войне 1941-1945 гг.”



**Дәүләтшин Нурмөхәмәт Мөбаракша улы**

Дәүләтшин Нурмөхәмәт Мөбаракша улы 1930 нчы елның 30 нчы июнендә Саба районы Югары Шытсу авылында туа. Бөек Ватан сугышы башланганда аңа 11 генә яшь була. 13 яшеннән башлап Нурмөхәмәт абый ат белән җир сукалый. 17 яшендә һәр гектардан 19 центнер уңыш алган өчен аны “Фидакарь хезмәт өчен” медале белән бүләклиләр.

1950-1953 нче елларда Нурмөхәмәт абый армия сафларында хезмәт итә. Аннан кайткач, ул чактагы колхоз рәисе Мусин Гадрахман аны Чәбки-Саба авылы амбарына клодовойчы итеп билгели.

“5 чакрым араны 8 ел буе ат белән йөреп эшләдек, аннары 30 ел буе Түбән Шытсу авылыннан ат арбасына салып ягулык ташыдык,” – дип искә ала Нурмөхәмәт абый. Соңгы 27 елда ындыр табагы мөдире вазифасын башкара ул.

Тынгы белмәс Нурмөхәмәт абый хәзер дә гел хәрәкәттә. Тормыш иптәше Тәслимә апа белән бәхетле картлык кичерә.





**Нәбиуллина (Зәйнуллина) Разыя Зәйнулла кызы**

Нәбиуллина (Зәйнуллина) Разыя Зәйнулла кызы 1931 нче елның 8 нче июнендә дөньяга килә. Саба районы Олы Саурыш авылында башлангыч мәктәптә 4 класс белем ала, 5-7 нче сыйныфларны Төбәк мәктәбендә укый. 1941 нче елда укытучылар сугыш башлануын хәбәр итәләр.

“Җәйгә чыгуга басудан черек бәрәңге җыеп, аны киптереп, он итеп ясап, шуңа әз генә чи бәрәңге кушып ашый идек, “ – дип искә ала Разыя апа. “Аякта чабата, өскә кияргә кием юк, аяклар юешләнгәч, носкиларны сыгып кия идек. Мәктәптән кайтуга бригадир басуга башак җыярга һәм кул белән борчак йолкырга алып китә иде”.

Сугыш тәмамлангач, 1951 нче елның 15 нче апрелендә Югары Шытсу авылына китапханәче булып эшкә урнаша ул. 1953 нче елда шул авыл егете Нурислам белән тормыш корып җибәрәләр. 3 малай тәрбияләп үстерәләр.

“Тормышлар бик тә авыр иде. Сыер асрап, май да ашый алмадык – базарга алып чыгып сатып заем түләдек, - дип күз яшьләре белән хәтирәләрен яңарта Разыя апа.

“Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 30, 40 еллыгына карата” медальләре белән бүләкләнә.

Бүгенге көндә Разыя апа ире Нурислам абый белән уллары Илдар, киленнәре Фәнзия тәрбиясендә бәхетле картлык кичерә.

 

**Нәбиуллин Нурислам Хидиятулла улы**

Нәбиуллин Нурислам Хидиятулла улы 1928 нче елның 15 нче мартында Югары Шытсу авылында дөньяга килә. 1936 нчы елда I класска укырга керә, 5 класс белем ала.

"Без, малайлар, колхоз кырларында җиң сызганып эшли идек: басуда тубал күтәреп, чәчү чәчтек, тырмаладык. Нинди авыр эш бар, барысын да эшләдек," – дип искә ала ул.

1948 нче елда Нурислам абыйны армиягә алалар. Анда 4 ай укыткач, шахтага җибәрәләр. Армиядә хезмәт итеп, 4 ел Кузбассның Прокофьевск шахтасында эшләп, колхозга эшкә кайта ул. 20 ел буе йөк машинасын иярли, аннан килеп, 20 ел тегермәндә эшли.

1953 нче елның 21 нче гыйнварында Олы Саурыш кызы Разыя белән тормыш корып җибәрәләр, үзләренә яңа йорт салып, башка чыгалар.

Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 50, 55, 60, 65, 70 еллыгы өчен медальләре белән бүләкләнгән ул.

"Менә шушы Саурыш кызы белән 63 ел бергә гомер иттек инде, ничек кенә хәйлә табып, тагын бераз яшәргә," – дип шаярта Нурислам абый. Алар хатыны Разыя апа белән 3 ул тәрбияләп үстерәләр. Бүгенге көндә Нурислам абый уллары Илдар, киленнәре Фәнзия тәрбиясендә бәхетле картлык кичерә.





**Хәйруллина (Ибатуллина) Суфия Вәли кызы**

Хәйруллина( Ибатуллина) Суфия 1931 нче елның 8 нче гыйнварында Югары Шытсу авылында Габделвәли һәм Фатима гаиләсендә дөньяга килә. Суфия апага 9 ай булганда әтисе сугышка китә. Әниләре балаларын узе генә тәрбияләп устерә. Суфия апа әнисен гомере буе хөрмәт итеп, рәхмәтле булып яши. Сугыш башлануын да ул әнисеннән белә.

«Сугыш елларында тормышыбыз авыр булды: мин бер генә сыйныф белем алдым, чөнки сугыш башланды, шуннан соң кешеләрдә бала карадым. Хәзерге вакытта мин укый да, яза да белмим. Ашарга басудан черек бәрәңгеләр эзли идек, басу таптап йөрмәгез дип безне куып җибәрәләр иде, ләкин әни безгә ничек тә булса ашарга таба иде,» - дип искә ала Суфия апа.

Сугыш беткән, дигән хәбәрне Суфия апа амбарда каравыл торганда ишетә. Хөсәен (фамилиясен хәтерләми) Тубән Шытсуга төшкәч ишетеп, бу хәбәрне алып кайта. Май ае, бик тә кояшлы көн була.

Суфия апа 1949 нчы елдан алып 10 ел фермада эшли. 1959 нчы елда клубка җыештыручы булып эшкә урнаша.

1958 нче елда тормыш юлын Харис абый белән бәйләп, 56 ел бергә гомер кичерәләр һәм ике кыз бала устерәләр.

Хәзерге көндә Суфия апа Югары Шытсу авылында гомер кичерә. Туганнары, кызы, оныклары, күршеләре дуслары аның һәр көнне хәлен белеп торалар. «Авылдашларым да, күршеләрем дә мине якын итәләр, мин аларга бик тә рәхмәтлемен,» - ди Суфия апа.





**Зәйнуллина (Галимуллина) Рәисә Галимулла кызы**

Югары Шытсу авылында яшәүче Зайнуллина (Галимуллина) Рәйсә Галимулла кызы 1929 елның 1 июлендә Саба районы Олы Арташ авылында урта хәлле крестьян гаиләсендә туган. Гаиләдә 6 бала үсәләр. Бөек Ватан сугышына 1927 нче елгы иң олы абыйлары Шәрифулла алына. Сугыш бетәрәк, аның хәбәрсез югалганлыгын хәбәр итәләр.

Гаиләдә иң олы бала булганга, барлык эшләр дә Рәйсә апа җилкәсенә төшә: әтисенә ияреп, утын әзерләү, печән чабу, гаиләне туйдыру өчен басуда ашлык җыю, кич утырып, солдатларга дип, оек-бияләйләр бәйләү, әле вагон төяргә, әле урман кисәргә барулар...

“Колхозга да эшкә кушалар иде. Атларга камыт кидерергә картлар булышты, чөнки буй җитми иде. Сугыш берәүне дә аямады: өстә - телогрейка, аякта - чабата, ачлы –туклы тормыш бөтен кешенеке бертөсле иде,” - дип, янә үткәнгә кайта ул.

Халыкның тырышлыгы бушка китми: күптән көтелгән Җиңү көне килә. Якыннары үлеп калганнар - сугыш беткәнгә сөенеп; ирләре, уллары кайткан гаиләләр газизләрен исән-сау күрү бәхетеннән елый ул көнне.

Сугыштан соң Рәйсә апа төрле эшләрдә эшли: кул чалгысы белән өлешләп бүленгән борчак чабулар, кул белән бәрәңге алулар, урманда печән чабулар, чөгендер үстерүләр, хәтта, кукуруз басуларын кул белән утаулар да калмый ул чорларда.

1956 нчы елның гыйнвар аенда ул Югары Шытсу авылына килен булып төшә. Тормыш иптәше Миндрахман белән биш бала тәрбияләп үстерәләр.

Рәйсә апа тырышып эшләгәне өчен “1 Май” исемендәге колхоз биргән “Похвальная грамота”ларын, Бөек Җиңүнең 30,40,55,60,65,70 еллыгына бирелгән ”Юбилей медале”н бүген дә кадерле истәлек итеп саклый.

Бүгенге көндә аның өч кызы, бер улы, 9 оныгы, 7 оныкчыгы хәлләрен белеп, ярдәм итеп торалар. Менә шулай яңа туган һәр көнгә сөенеп, балалары, оныклары өчен горурланып, яшьләрчә җитезлек белән яши ул.



**Мәүлетҗанов Мөхәмәтгали Мәүлетҗан улы**

Мәүлитҗанов Мөхәмматгали Мәүлитҗан улы 1927 нче елның 26 нчы мартында Саба районы Югары Шытсу авылында эшче гаиләсендә тугызынчы бала булып дөньяга аваз сала.

Бөек Ватан сугышы башланганда 14 яшьлек яшүсмер, сугышка китү теләге белән, яшьтәше Абдуланны ияртеп, военкоматка килә. Ләкин анда Мөхәмматгали бабайны һәм яшьтәшен кире борып кайтаралар. Тылда күргән михнәтле тормышны Мөхәмматгали бабай беркемгә дә теләми: алабута җыеп, аннан  икмәк пешерү, черек бәрәңгедән ашарга ризык әзерләү, ачлык, ялангачлык, шәһәргә барып икмәк ташулар, иген кырында иртәдән кичкә кадәр хезмәт итүләр, урманда агач кисүләр, окоп казулар...

Сугыштан Мөхәмматгали бабайның абыйсы һәм әтисе исән-имин кайтсалар да, сугыш хәсрәте озак елларга сузыла. Авылда ачлык, ирләр саны аз, гадәти тормышка кайту өчен авыл халкына бик нык тырышырга туры килә.

Мөхәмматгали  бабай иптәше Мәрфуга белән 1952 елда кушылып, тормыш корып җибәрәләр. 1953 нче елның 26 нчы августында беренче балалары - Сабур исемле уллары туа. Икенче балалары, кызганыч, озын гомерле булмый, дөнья куя. Шуннан соң бер-бер артлы тагын 4 бала дөньяга аваз сала.

Мөхәмматгали бабай атлар карауда, колхоз көтүен көтүдә, колхоз фермасын күтәрүдә үзеннән зур өлеш кертә. Аңа тыл ветераны буларак бирелгән наградалар икәү:
Беренчесе – Бөек Ватан сугышының 65 еллыгына бирелгән юбилей медале.
Икенчесе – Бөек Ватан мугышының 70 еллыгына бирелгән юбилей медале.

Гәрчә Мөхәмматгали бабай 5 класс белемле генә булса да бик тырыш, акыллы, сүзгә оста, җор телле, ир-егет, балаларының әтисе, бабай булып гомер юлын үтә.





**Хәбибуллина (Габдрәкыйпова) Мәликә Габдрәкыйп кызы**

Хәбибуллина (Габдрәкыйпова) Мәликә Габдерәкыйп кызы 1926 нчы елның 13 нче февралендә Саба районы Түбән Шытсу авылында урта хәлле Габдерәкыйп белән Сәлимә семьясында беренче бала булып туа. Түбән Шытсу мәктәбендә 3 класс белем ала.

Сугыш башланганын авылда ишетә Мәликә апа. Туып-үскән җирләрен калдырып, бер көндә 7 кеше сугышка чыгып китә. Алар арасында Мәликә апаның әтисе дә була. Һәркем өчен авыр еллар башлана. Атлар карау, сарык фермасында, ат белән басуда эшләү, сукалау, учма бәйләү, урак уру - барысын да үз башыннан үткәрә Мәликә апа. Шәмәрдән урманында эшләү, ат белән Шәмәрдәнгә икмәк ташу эшен дә башкара ул. Ул чакта кеше өендә яшәп, өйдән алып барган ризыкларны ашап тора Мәликә апа. Җылы кием- салым да бик аз була.

Сугыш беткәнен урман кискәндә, Шәмәрдәндә ишетә ул. Шул көннән башлап, поезд белән солдатлар кайтканын көн дә көтә башлый, Яралылар кайта башлагач, әтисенең дә алар арасында булуына өметләнә. Тик аның, Омскта җирләнде, дигән хәбәре килә.

1951 нче елның көзендә Югары Шытсу авылында яшәүче Тимершәех исемле егеткә кияүгә чыга. Тормыш иптәше белән бергә 21 ел яшиләр, 4 кыз бала үстерәләр. Мәликә апа гомере буе колхозда эшли.

Бүләкләре:

Бөек Җиңүнең 40, 50, 55, 60, 65, 70 еллыгына бирелгән медальләр, Ветеран труда медале, Службу в тылу в годы ВОВ

Хәзерге көндә Югары Шытсу авылында яшәүче кече кызы Мөршидә белән кияве Тәлгать гаиләсендә бәхетле картлыкта яши Мәликә апа.





**Мусин Хәниф Габдрахман улы**

Мусин Хәниф Габдрахман улы Саба районы Югары Шытсу авылында Габдрахман һәм Фәйрүзә гаиләсендә 1932 елның 18 маенда дөньяга килгән.

Аның әтисе Габдрахман Мусин “Беренче май” колхозы председателе булып эшләгән. 1935-1937 елларда “Беренче май” колхозына республикада тиңнәр булмый, колхозчылар бер хезмәт көненә 7 кг исәбеннән ашлык алалар.

Сугыш башланган көнне Югары Шытсу халкы клубка җыела. Бу көннәрдә авылның 60лап ире Казан- Бөгелмә юдында төзелештә була. Аларны да авылга чакырып алалар. Дистәләгән ир-ат клубта ук гариза язып, үзен сугышка җибәрүне сорый. Бу вакытта Хәниф Мусинга 9 яшь була. Малайларның җилкәсенә сугыш нужасы менеп кунаклый. Алар печәндә чүмәлә тарттыралар, уракка төшкәч, көлтә ташыйлар, Шәмәрдәнгә ашлык илтәләр. Олылар да, үсмерләр дә һәр бөртекнең дошман йөрәгенә пуля булып кадалуын, икмәкнең җиңү сәгатен якынайтырга булышуын бик яхшы аңлыйлар.

“Сугыш бетте, без җиңдек!” дигән хәбәрне Түбән Шытсу авыл Советына Сабадан шалтыратып әйтәләр. Хәниф Мусинның әтисе, сугыштан бер кулын өздереп кайтса да, колхоз белән җитәкчелек итә. Колхоз гөрләп эшли, күп ярышларда республикада алдынгылыкны бирми. Габдрахман Мусинга ул елларда “Хезмәттәге батырлык өчен” медален тапшыралар.

Хәниф Мусин колхозда балта остасы булып эшли. Кешеләргә бура бурый, йортлар сала, тәрәзә йөзлекләре, бизәкләп урыс капкалары ясый. Ул сугыш бетүнең юбилей даталарына багышлап чыгарылган барлык медальләр белән дә бүләкләнә. Тормыш иптәше Фәрбизә белән 1 кыз, 1ул тәрбияләп үстерәләр. Оныклары бар. Бүгенге көндә Югары Шытсу авылында яши.





**Габдрахманова Миннерузия Билал кызы**

Габдрахманова Миннерузия Билал кызы 1932 нче елның 20 мартында Саба районы Югары Шытсу авылында Билал абый һәм Шәмсебәдәр апа семьясында беренче бала булып дөньяга килә. Аның бала чагы авыр елларга туры килә. Бөек Ватан сугышы башланганда аңа нибары 9 яшь була.
Әтиләрен сугышка алып китәләр. Әниләре Шәмсебәдәр апа дүрт бала белән кала. Ул колхозда тегермән тарта, колхозчыларга ипи сала, балаларын шулай туйдыра. Аларның бәхетенә әтиләре сугыштан исән-сау кайта.
Рузия апага бик яшьли авыр эшләрдә эшләргә туры килә. Ул тракторда сукачы булып эшләгән еллары турында бүген дә шаккатып сөйли. “Бервакыт төнге сменада эшләгәндә тракторыбыз ватылды. Шәмгун абый мине авылга бригадирларга кайтарып җибәрде. Төнлә белән берүзем ничек курыкмыйча кайтканымдыр. Саба тау башына кайтып җиткәч ял итәргә утыруым бүген дә күз алдымда,”- ди ул. Рузия апа шулай ук урман кисү эшендә дә катнаша. Лесхоз, Лаеш, Мәшнәк урманнарында эшләргә туры килә аңа. Унар көн буе өйләренә кайтмыйча эшлиләр алар. Аякларында чабата, тамаклары ачлы-туклы була, ләкин түзәләр. Квартирада биш кыз торалар, кич белән җилкәләренә салып мичкә ягу өчен чи каен утыны алып кайталар. “Юан имәннәрне кул пычкысы белән ничек кискәнбездер. Каян көч килгәндер”,- ди ул.

Шулай бер-бер артлы еллар үтә. 1955 нче елда ул тормышка чыга. Ул елларда басуны кул белән чабарга бүлеп бирәләр. Артышлык өстендәге басуда кул белән борчак чабулары турында бүген дә искә ала Рузия апа. Бер эштән дә куркып тормый ул, кайда кушсалар шунда эшли.

Аннан соң лаеклы ялга чыкканчы фермада дунгызлар һәм сарыклар карый. Авырлыклар да читләтеп үтми аны: тормыш иптәшен югалта, бала хәсрәте дә күрә ул. Ләкин авырлыклар алдында югалып калмый.

“Без авырлыкларны күп күрдек. Бүгенге тормышыбыз аллага шөкер. Тамагыбыз тук, өстебез бөтен, акчаны өйгә китереп бирәләр. Без күргәннәрне бүгенге яшь буынга күрергә язмасын, сугышлар гына булмасын.”- ди ул.




**Галимова (Әхмәтшина) Гәндәлиф Әхмәтша кызы**

Галимова (Әхмәтшина) Гәндәлиф Әхмәтша кызы 1931 нче елның 13 нче сентябрендә Югары Шытсу авылында колхозчы гаиләсендә дөньяга килә. Гәндәлиф апа өч класс белем ала.

Сугыш башлангач, сугышка абыйсын озата. Хәзерге вакытта да абыйсыннан килгән хатларны укып, аны искә ала. Сугыш вакытларында бик күп эшләрдә эшли Гәндәлиф апа: колхозда көлтә бәйли, урак ура, кул белән борчак чаба, урман кисә. Бу елларда барлык эш хатын-кызлар, балалар кулына төшә.

“Әллә ничә тапкыр ямалган күлмәкләрне киеп эшләдек, ашарга кычытканнар эзләп, шулардан аш пешерә идек,”- дип искә ала Гәндәлиф апа.

1976 елда Гәндәлиф апа Якуп абыйга кияүгә чыга һәм өч ятим бала үстерә.

Хәзерге вакытта Гәндәлиф апа Югары Шытсу авылында яши. Туганнары, балалары аның гел хәлен белеп торалар.





**Фәрләхова (Заһидуллина) Шәмсикамал Дәүләтгәрәй кызы**

Фәрләхова (Заһидуллина) Шәмсикамал Дәүләтгәрәй кызы 1927 нче елның 22 нче декабрендә Югары Шытсу авылында колхозчы гаиләсендә туа. Ул гаиләләрендә иң өлкән бала була. 3 класс белемне Югары Шытсуда, ә 4 нче класс белемне Түбән Шытсу авылында алган. Сугыш башланган көнне бик яхшы хәтерли Шәмсикамал апа: ул көнне Өч Нарат базарына барган була һәм шунда сугыш башлануын андагы кешеләрдән ишетә. Озак та тормый сугышка әтисен - Дәүләтгәрәй абыйны озаткан.

Сугыш вакытында урман эшендә эшләгән, окоп та казыган, вагон да төягән Шәмсикамал апа.

Сугыш беткәннән соң, Фәрләхов Тимершаех белән тормыш корып җибәрәләр. Аларның биш балалары туа.

Хәзерге вакытта улы Әхәт абый һәм килене Әлфия апа белән тыныч тормышта яшиләр. Башка балалары да Шәмсикамал апаның хәлен беләләр. Оныклары да аны бик яраталар, һәр җәй саен авылга кунакка кайталар.



**Гайфуллина (Баһманова) Мәгрифә Баһман кызы**

Гайфуллина (Баһманова) Мәгрифә Баһман кызы 1931 нче елның 7 нче февралендә Югары Шытсу авылында урта хәлле гаиләдә туа.Үзенең туган авылында 4 класс белем ала. "Яп-якты бер көндә яшен яңгыраган төсле булды,”- дип искә ала Мәгрифә апа сугыш башлануын. Сугыш фронтына әтиләрен озаткан гаиләгә бик авырга туры килә ул елларда.

Ачлыктан үлмәс өчен, Мәгрифә апа фермада сарыкчылыкта эшли. "Эштән кайтуга, өйдәге бөтен кешенең чын күңелдән сөенгәнен күргәч, сугыш беткәнен анладым мин", - дип искә ала Мәгрифә апа. Сугыш беткәннән соң ул Гайфуллин Шафигуллага кияүгә чыга, алар икесе бергә 4 бала карап үстерәләр. Ире белән колхозда төрле эштә эшлиләр.

Бүгенге көндә Мәгрифә апа лаеклы ялда. Югары Шытсуда малае Гайфуллин Таһир белән яши.





**Әбүбәкирова (Зиннатуллина) Хәтимә Зиннатулла кызы**

Әбүбәкирова (Зиннатуллина) Хәтимә Нәбиулла кызы 1930 нчы елның 2 нче сентябрендә Югары Шытсу авылында колхозчы гаиләсендә дөньяга килә. Үзенең туган авылында 4 класс белем алган. “Сугыш башлануын миңа әнием әйтте, минем абыемны алып китүен күз алдына китергәч, елый башлады”,- дип искә төшерде Хәтимә апа. Сугыш вакытында Хәтимә апа 6 ел фермада эшләгән. Көн саен киндер штан, күлмәк киеп йөргәннәр. Хәтимә апа фронтка үзенең абыен Абүбәкиров Гыйльмулланы озаткан.

Сугыш бетүе. “Ул көнне мин бик әйбәт хәтерлим-дип искә ала Хәтимә апа-мин капка төбенә чыгуга ниндидер бер таныш тавыш ишетелде. Ә ул Хөсаенов абый икән. Ул бөтен авылга: “Сугыш беткән! Сугыш беткән!”дип кычкырып җибәрде. Шул ук минутта авылдагы хатын-кызлар бер тауга җыелдылар. Менә хәзер фронттан кайтырлар дип, юлга карап тордылар алар. Кайбер хатын-кызлар кайтмаячагын белгәндәй, елый башладылар.”

Хәтимә апа 1952 елның 1 гыйнварында Зиннәтуллин Кәшип абыйга кияүгә чыга. Алар икесе бергә 5 бала тәрбияләп үстерәләр. Бу вакытларда төрле эштә эшлиләр: колхозда, ындырда.

Бүгенге көндә Хәтимә апа лаеклы ялда. Югары Шытсуда үзенең кызы Юнысова Кәүсәрия гаиләсе белән яши. Хәтимә апаның “Ветеран труда” исемле медале бар. “Киләчәктә күкләребез гел аяз, тормышыбыз тыныч булсын иде!”- дип теләкләр тели Хәтимә апа.



## Әминова (Сәләхетдинова) Зәнифә Сәләхетдин кызы

Әминова (Сәләхетдинова) Зәнифә 1927 елның 2 сентябрендә Елыш авылында туа. 1934 нче елда укырга керә ул. Тик беренче классны укып бетерүгә, басуга чүп утарга җибәрәләр, бодай җирендә билчән утыйлар.

“Элек перчатка юк, билчән энәсе кулга кадала иде. 5 классны тәмамлагач, атлы молотилка алдына көлтә ташып торырга куйдылар”,- дип искә ала Зәнифә апа.

7 классны тәмамлагач, Шәмәрдән урманына агач кисәргә җибәрәләр. Урман эчендә землянкада торалар алар.

“Аякларда чабата. Чабата тишелгәч, урманнан юкә агачыннан мунчала алып кайтып, шуның белән тегә идек. Эшкә барганда кесәгә бәрәңге тыгып барабыз. Ботаклардан учак ягабыз, шуның күмеренә үзебезнең бәрәңгеләргә тамга салып күмәбез. Землянкага кайткач, алабута күмәчен су белән ашыйбыз. Бүрәнә ярыгына йомычка кыстырып чабаталарны кибү өчен шуңа элә без. Аска телогрейка, өскә шәл ябынып йоклыйбыз”,- дип сөйли Зәнифә апа урман кисү эшендә күргән авырлыклар турында.

Сугыштан соң да Зәнифә апа төрле авыр эшләрдә эшли. Авырлыклардан курыкмый. Әминов Абдулла белән тормыш корып, 5 бала үстерәләр.

“Аллага шөкер, бик авырлык белән яшәсәм дә, картлык көнемдә рәхәт яшим. Балаларым бик әйбәт булдылар. Һәр атна саен кайтып хәлемне белеп торалар. Бүгенге көндә икенче малаем тәрбиясендә торам. Без күргәннәрне башкаларга күрергә язмасын иде,”- ди Зәнифә апа.

Бүләкләре:
"За доблестный труд в период ВОВ 1941-1945 гг."
«СОРОК ЛЕТ ПОБЕДЫ ВЕЛИКОЙ ОТЕЧЕСТВЕННОЙ ВОЙНЕ 1941-1945 гг.»
«50 ЛЕТ ПОБЕДЫ В ВЕЛИКОЙ ОТЕЧЕСТВЕННОЙ ВОЙНЕ 1941-1945гг.»
Памятный знак Республики Татарстан в честь 55-й годовщины Победы в Великой Отечественной войне 1941-1945гг.
« 60 ЛЕТ ПОБЕДЫ В ВЕЛИКОЙ ОТЕЧЕСТВЕННОЙ ВОЙНЕ 1941-1945гг.»

 

## Тимергалиева (Даутова) Миннегәләм Сираҗетдин кызы

Тимергалиева (Даутова) Миннегәләм Сираҗетдин кызы 1930 нчы елның 27 нче гыйнварында Саба районы Елыш авылында урта хәлле крестьян гаиләсендә туа. Башлангыч белемне Елыш авылында ала. 5 нче класска Баландыш җидееллык мәктәбенә бара. 7 классны тәмамлый.

Миннегәләм апа бик тере, эшкә батыр була. Бала вакыттан ук печән кабартырга йөри. 6- 7 сыйныфларда укыганда төп колхоз эшенә алына. Күбрәк ат белән эшләргә ярата Миннегәләм апа. Урман кисү эшләрендә катнаша.

“Нормасы бик зур иде. Ашарга ипи юк. Бәрәңгене уып бәрәңге ипие пешерә идек. Аякта чабата, киярге кием юк”,- дип искә ала ул үткәннәрне.

Сугыштан соң да тормыш җиңеләйми. Миннегәләм апа башта бригадир, аннары кладовщик була. 1955 нче елның сентябрендә үзләренең авылы егете Әбелгәска томышка чыга. Ул алдынгы механизатор була. Алар 4 бала тәрбияләп үстерәләр.

“Кечкенәдән эшләп үсәргә туры килде. Бөтен йорт эшләре безгә кала иде,”- ди ул.

Хәзерге вакытта Миннегәләм апа Теләче районы Баландыш авылында кызы Әминә белән яши. Ул бик бәхетле, чөнки бүгенге көндә 7 оныгы, 9 оныкчыгы бар. Тылда күрсәткән тырыш хезмәте өчен Миннегәләм апа "За доблестный труд в период ВОВ 1941-1945 гг." медале белән бүләкләнә.

“Дөньялар тыныч булсын, сугыш афәтләре булмасын. Балалар ятим үсмәсеннәр, күз яшьләре түкмәсеннәр. Безнең яшь вакытта күргәннәр бүтән кабатланмасын иде”, - дип тели Миннегәләм апа.



## Ситдикова (Биктимерова) Хәкимә Гыйлемхан кызы

Ситдикова (Биктимерова) Хәкимә Гыйлемхан кызы 1930 елның 1 нче гыйнварында Сат-Ключ авылында колхозчы гаиләсендә туа. Елыш башлангыч мәктәбендә укый. Баландыш авылына йөреп 7 классны тәмамлый. Мәктәпне тәмамлагач, колхозда төрле эштә эшли.

Барлык сугыш чоры балалары язмышы белән аваздаш Хәкимәнең дә язмышы. Аңа урак урырга да, җитен йолкырга да, урман кисәргә дә туры килә. Ул авырлыкларга бирешми. Сугыш елларында күргән авырлыклар өстенә сугыштан соңгы еллар авырлыгы өстәлә. Абыйсы сугыштан кайтмый, ә әтисе бик нык авырый. Ашарга азык, кияргә кием булмый. Яз көннәрендә черек бәрәңге җыеп ашаулар да аның тормышын читләтеп үтми.

1954 нче елда Елыш авылы егете Кадыйрга кияүгә чыга Хәкимә апа. Тормыш иптәше белән 3 бала тәрбияләп үстерәләр үстерәләр. Хәзерге көндә Хәкимә апа Елыш авылында яши.

Бүләкләре:

"За доблестный труд в период ВОВ 1941-1945 гг."

«СОРОК ЛЕТ ПОБЕДЫ ВЕЛИКОЙ ОТЕЧЕСТВЕННОЙ ВОЙНЕ 1941-1945 гг.»

«50 ЛЕТ ПОБЕДЫ В ВЕЛИКОЙ ОТЕЧЕСТВЕННОЙ ВОЙНЕ 1941-1945гг.»

Памятный знак Республики Татарстан в честь 55-й годовщины Победы в Великой Отечественной войне 1941-1945гг.

« 60 ЛЕТ ПОБЕДЫ В ВЕЛИКОЙ ОТЕЧЕСТВЕННОЙ ВОЙНЕ 1941-1945гг.»

« 65 ЛЕТ ПОБЕДЫ В ВЕЛИКОЙ ОТЕЧЕСТВЕННОЙ ВОЙНЕ 1941-1945гг.»



## Кәлимуллин Заһидулла Кәлимулла улы

Кәлимуллин Заһидулла Кәлимулла улы 1929 нчы елның 5 нче октябрендә Түбән Шытсу авылында, эшче гаиләсендә туган. Әтисе Кәлимулла, әнисе Мәрьямбикә гаиләдә 5 бала тәрбияләп үстерәләр.

Заһидулла абый 4 класс белем алган.

"Сугыш башлангач колхозда тырма тырмалау, сука сукалау, барлык колхоз эшендә дә йөрдем. Җәй көне шул яшел масса- кычыткан белән туендык инде, ашарга юк инде ул, әземе-күпме бәрәңге, язга чыккач өшегән бәрәңге җыеп ашадык. Ярый колхозның алып бетермәгән җирләре була торган иде. Безнең гаиләдән сугышка китүче булмады. Сугыш бетүен радиодан ишеткәнбездер инде. Сугыштан соң фермада эшләдем, тегермән тарттым. Кыш көне күп вакыт урман чыгаруда эшләдем," - дип искә ала ул.

1956 нчы елның 9 нчы маенда Хуҗина Сәвия Хуҗа кызы белән гаилә кора Заһидулла абый. Бергәләп 4 бала үстерәләр: 3 егет, 1 кыз. Бүгенге көндә төпчек улы Ринат гаиләсендә гомер итә.

Бүләкләр:

Җиңүнең 30, 40, 50, 60, 70, 75 еллыгына бирелгән медальләр.

1981 елда “Ударник коммунистического труда” званиесе бирелә.

1975 елда “Победитель социалистического соревнования 1975 года” удостоверениесе бирелә.



## Юнысова Нәфисә Галимулла кызы

Юнысова Нәфисә Галимулла кызы 1920 нче елның 12 нче гыйнварында дөньяга килә. Бик яшьли ятим калып, Нәфисә апа олы абыйсы Шәрипҗан белән җиңгәсе тәрбиясендә үсә. 18 яшендә Галим исемле егеткә кияүгә чыга.

1941 елда ирен, Арча кырында йортлар салу өчен кеше вербовать итәргә дип, Казанга җибәрәләр. Гаилә дә шунда күченә. Ул вакытта беренче балалары Нәсимә туган була инде. 1941 нче елның җәендә Галимне 10-15 көнгә өйрәнүләргә дип хезмәткә чакыралар. Тик ул аннан кайтып җитә алмый, 22 нче июнь көнне сугыш башлана. Нәфисә апа Казанда тагын ике айлап тора әле. Аннары абыйсы Шәрипҗан сеңлесен ат белән килеп ала.

Авылга кайту белән колгозга эшкә чыга Нәфисә апа. "Сугыш чыккан елны кыш бик буранлы булды, - ди ул. - Зөһрә исемле хатын белән киптерергә көлтәдә ашлык ташыдык. Баланы Сабира җиңгигә калдыра идем. Язга чыккач, Шәмәрдәннән чәчүлек ашлыкны арбага салып ташыдык. "Үрнәк"совхозыннан атларга салам алып кайта идек. Уракка чыккан вакытларда балаларны тартып алып бардык. Бөтен җыйган ашлык сугышка китте. Кайвакыт, ашыгыч булганда, икмәкне монда чистартырга өлгермәдек. Шәмәрдәнгә ат белән алып барып, шунда чистарттык. Җөри каршыннан Баландышка хәтле юл эшенә йөрдек, көне буе эшлибез, ашарга бер тапкыр ипи алып киләләр иде".

Ире Галим сугышта 4 ел да 3 ай йөреп, яраланып кайта, бер ай тирәсе Шәмәрдән больницасында ята. Терелеп чыккач, аны Сабага председатель итеп куялар. Уллары Нәгыймулла да шунда туа.

Алар Сабада 3 ел торалар. Авылга кайткач, Нәфисә апа яңадан колгозга эшкә чыга. Ире белән 5 бала үстерәләр. Тик аңа 47 яшь булганда, Галим абый вафат була.

Хәзерге вакытта Нәфисә апа улы Наил һәм аның гаиләсе белән бергә яши.



**Галимова Шәмселхәят Хәсән кызы**

Галимова Шәмселхәят Хәсән кызы 1927 нчы елның 21 нче сентябрендә Югары Шытсу авылында, эшче гаиләсендә туган. Әтисе Хәсән, әнисе Сабира гаиләдә 6 кыз бала тәрбияләп үстерәләр. Шәмселхәят апа иң өлкән бала була. Башлангыч белемне үзенең туган авылы мәктәбендә ала.

Сугыш башланганда Шәмселхәят апага бары 14 яшь кенә була әле. Гаиләдә иң олы бала булганга, барлык эшләр дә аның җилкәсенә төшә: утын әзерләү, печән чабу, гаиләне туйдыру өчен басуда башак һәм черек бәрәңге җыю һәм башка эшләр.

Шәмселхәят апа барлык сугыш чоры авырлыкларын үз җилкәсендә күтәрә, бик яшьли авыр эшләрдә эшләргә туры килә. Аңа урак урырга да, көлтә бәйләргә дә, урман кисәргә һәм вагон төяргә дә йөри. Ул авырлыкларга бирешми. Сугыш елларында күргән авырлыклар өстенә сугыштан соңгы еллар авырлыгы өстәлә.

Сугыштан соң да тормыш җиңеләйми. Шәмселхәят апа шактый еллар “Беренче май” колхозында тракторда эшли. Ул тракторда эшләгән еллары турында бүген дә шаккатып сөйли. Булачак ире Сөләйман абый белән дә тракторда эшләгән вакытта танышылар һәм матур гаилә коралар. Сөләйман абый алдынгы механизатор була. Алар 3 малай тәрбияләп үстерәләр. Куйган тырышлыклары өчен “Фидакарь хезмәт өчен” медале белән бүләклиләр.

Лаеклы ялга чыккач та Шәмселхәят апа байтак еллар Йосыф Алан урманына агач үсентеләре үстерә торган питомникка эшкә йөри. Буш вакытларында балаларына һәм авылдашларына җылы бияләй һәм оекбашлар бәйли.

Бүгенге көндә Галимова Шәмселхәят Хәсән кыз Йосыф Алан авылында кече улы Мәдәррис һәм килене Рәмзия гаиләсендә бәхетле картлык кичерә.



## Гайсин Шаһимулла Гайсә улы

Гайсин Шаймулла Гайсә улы 1932 нче елның 5 нче гыйнварында Түбән Шытсу авылында туган. Гаиләдә 5 бала үскәннәр, 5 класс белеме бар. Сугыш вакытында колхозда төрле эшләрдә эшләгән Шаймулла абый. Ашау - ачлы-туклы, киенергә юньле кием юк. Сугышка әтисе Җиһаншин Гайсәне озаталар, кызганычкам каршы, ул сугыштан кайтмый. Зарыгып көткән "Сугыш бетте!" дигән хәбәрне исә Нуриәхмәт бабайдан белә (ул авыл советында дежур торган була).

Сугыштан соң 1951- 1954 нче елларда армия сафларында хезмәт итә Шаймулла абый. Шул елның көзендә Үрнәккә (Арча районы) комбайнга укырга бара. Аннары МТСта эшли башлый. 1958 нче елда Түбән Шытсу авылы кызы Асиягә өйләнә, 3 бала үстерәләр. 1965 нче елда Пермь ягына шахтага китәләр. 25 ел шахтада эшли Шаймулла абый. 1995 нче елда кире туган авылы Түбән Шытсуга әйләнеп кайталар.

Бүләкләре:

«ЗА ДОБЛЕСТНЫЙ ТРУД В ВЕЛИКОЙ ОТЕЧЕСТВЕННОЙ ВОЙНЕ 1941-1945гг.» от 11.03.1994 г. (Пермь)

«50 ЛЕТ ПОБЕДЫ В ВЕЛИКОЙ ОТЕЧЕСТВЕННОЙ ВОЙНЕ 1941-1945 гг.» от 22.03.1995 г.

Памятный знак РТ в честь 55-й годовщины Победы в Великой Отечественной войне 1941-1945гг.

Медаль «60 ЛЕТ ПОБЕДЫ В ВЕЛИКОЙ ОТЕЧЕСТВЕННОЙ ВОЙНЕ 1941-1945 гг.»

Медаль «65 ЛЕТ ПОБЕДЫ В ВЕЛИКОЙ ОТЕЧЕСТВЕННОЙ ВОЙНЕ 1941-1945 гг.»



## Габдрахманов Салих Габдрахман улы

Габдрахманов Салих Габдрахман улы 1932 нче елның 22 нче августында Түбән Шытсу авылында туа. Шушы авылда ул, 8 яшьтән мәктәпкә кереп, 4 класс белем ала. Сугыш башланганда бала гына була Салих абый: авылда чәчүдә эшли, пар атлар җигеп, Шәмәрдәнгә эшкә йөри, Явлаштауда урман ташый.

1951 нче елны ул армиягә китә һәм 1954 нче елда исән-имин әйләнеп кайта. Аннан кайткач, машинист таныклыгы алу өчен махсус курсларга укырга йөри. Укып бетергәч, комбайнчы булып эшли башлый. Нәкъ менә шушы эше өчен Салих абый бик күп медальләргә лаек булган, район буенча ике ел буе беренчелекне алган.

«Яшь вакытта без басудан кайтмадык та – гел көнне шунда үткәрдек: көлтә ташыдык, шунда ашлык җыеп йөрдек. Өйгә дә кайтып тормый идек – эскерт кырыенда йоклый идек,»- дип искә ала ул шул көннәрне.

Ачлы – туклы яши ул чор кешеләре. «Сезнең хәзер иртә белән торуга ашарга бөтен әйберегез бар. Ул вакытта без, иртәрәк торып, кычыткан яки алабута эзли идек. Шуннан аш пешереп ашый идек,»- дип сөйли Салих абый.

Салих абый тормыш иптәше Нәсимә апа белән дүрт бала тәрбияләп үстерәләр.

Тылда армый-талмый хезмәт күрсәткәне өчен Салих абый берничә медальгә ия була:

"За доблестный труд в период ВОВ 1941-1945 гг."
«За доблестный труд в ознаименование 100- летия со дня рождения В.И. Ленина»
"За трудовые отличия" (06.07.1966)



**Гәләвиев Әмин Гәләви улы**

Галәвиев Әмин Галәви улы 1931 нче елда, Сатыш авылында туып үсә. Аның гаиләсе урта хәлле була. Әмин абый 4 класс белем ала. Аңа 10 яшь булганда, ирләрне сугышка ала башлаганнар. Әмин абыйның әйтүе буенча, ул вакытта ныклап хәзерге кебек ашау да булмаган. “Элеккеге заманда эш тә эш иде инде”, - ди ул.

Сугыш беткән көнне бик яхшы хәтерли Әмин абый.

“Мин, иптәш егетем белән басуда эшли идем. Эшләгән чагымда, Мирсәй абыйның килеп безгә, сугыш бетте, дип әйткәне һаман да хәтеремдә,”- дип искә ала ул.

Салих абый тормыш иптәше Фәүзия апа белән 4 бала тәрбияләп үстерәләр:1 кыз, 3 малай. Хәзерге вакытта 3 малае да пенсиядә. Тылда күрсәткән хезмәте өчен, Бөек Җиңүнең 50, 55, 60, 65, 70 еллыгына карата бирелгән медальләре бар Әмин абыйның.

“Аллага шөкер, Фәүзия апаң белән тигез картлык кичерәбез. Әкренләп йөреп торгач, бик шөкер. Сугыш афәтен башка курергә язмасын! Сугыш вакытында сугышта, тылда көч куйганнар һәрвакыт искә алынсын. Дөньялар имин, тыныч булсын, амин!” – дип теләк тели Әмин абый.





**Фәләхова (Мутталиева) Һаҗәр Муталлый кызы**

Фәләхова (Муталлиева) Һаҗәр Муталлый кызы 1930 нчы елның 29 нчы декабрендә Түбән Шытсу авылында дөньяга килә. 1939 елда Һаҗәр апа 1 класска укырга бара. Дүрт ел белем алганнан сон ул, укуын туктатып, җиң сызганып эшкә керешә. 5 нче класстан 7нче класска хәтле белемен ул сугыш тәмамлангач дәвам итә.

1941 нче елның 22 нче июнендә Һаҗәр апаның әнисе, эштән кайтып, сугыш башланган, дигән кайгылы хәбәрне җиткерә. Авыл халкы өчен бу бик тетрәндергеч кайгы була.

Сугыш башлангач, бөтен авыл тормышы хатын-кызлар һәм балалар җилкәсенә төшә. Кырларда игеннәр тишелеп чыгу белән чүп утау, борчак һәм ясмык йолку, урак уру, учма бәйләү эшләрен башкарганнар алар. Ашау ягына килгәндә, шул көздән җыелып бетми калган, яз көне кар астыннан чыккан черек бәрәңге, сөт һәм алабута, кычыткан, ат кузгалагы ашыйлар. Ә иң татлысы бәрәңге күмәче була ул чакта.

1945 нче елның 9 нчы маенда, ындыр табагында эшләгәндә ишетеп, абыйсы Һаҗәр апага сөенечле хәбәр җиткерә: "Сугыш беткән!". Бу көн авылның икенче туган көне була.

Сугыштан соң Һаҗәр апа колхозда төрле эштә эшли. 1960 елда Фәләхов Әхмәтгаян Галимҗан улы белән гаилә корып, өч кыз үстерәләр. 1965 нче елда Түбән Шытсу сигезьеллык мәктәбенә техник хезмәткәр булып эшкә урнаша. Анда 20 елдан артык эшләп, лаеклы ялга чыга.

Бүгенге көндә кечкенә кызы Гүзәл һәм кияве Илшат гаиләсендә яши Һаҗәр апа. Аның хәзер өч баласы, сигез оныгы һәм биш оныкчыгы бар.

Бөек Ватан сугышы чорында тылдагы фидакарь хезмәте өчен Тыл Ветераны удостоверениесы, Ветеран труда медале, “30 лет Победы в ВОВ 1941-1945”, “40 лет Победы в ВОВ 1941-1945”, “50 лет Победы в ВОВ 1941-1945”, “60 лет Победы в ВОВ 1941-1945”, “65 лет Победы в ВОВ 1941-1945”, “70 лет Победы в ВОВ 1941-1945”, РТ Президенты исеменнән Җиңүнең 55 еллыгы хөрмәтенә истәлек билгесе белән бүләкләнгән.





## Шакирҗанова (Җәләлиева) Рәхимә Баһман кызы

Шакирҗанова (Җәләлиева) Рәхимә Баһман кызы Теләче районы Иске Җөри авылында 1925 нче елның 16 нчы октябрендә дөньяга килә. Үз авылларында 4 класс белем ала. Укуны дәвам итәр өчен Баландышка ат белән йөри йөрергә кирәк була, тик сугыш башланып, тормыш авырая, Рәхимә апа укуын ташларга мәҗбүр була. Ир-атлар сугышка китеп беткәч, эш хатын-кызлар җилкәсенә төшә. Рәхимә апа Явлаштау урманына агач кисәргә җибәрелә. Анда ел ярым эшләгәч, Казанга ФЗӨгә дип алып китәләр.

“Бик авыр еллар булды. Ашарга юк, кияргә юк, киемне киптереп кияргә дә урын юк. Вагоннарда яшәдек,” – дип искә ала Рәхимә апа.

1945 нче елның 15 нче маенда, сугыш бетүен хәбәр итеп, аны өенә кайтарып җибәрәләр. Бизгәк авыруы белән чирләгән Рәхимә апа өч ай авырып ята.

1948 нче елның 12 нче гыйнварында Югары Шытсу авылына килен булып төшә Рәхимә апа. Тормыш иптәше Шәрипҗан абый белән 4 бала тәрбияләп үстерәләр алар. Гомере буе колхозда эшләп, лаеклы ялга чыга ул. 1980 нче елда сугыш вакытында күрсәткән фидакарь хезмәте өчен “Хезмәт ветераны” медале белән бүләкләнә.

Бүгенге көндә Югары Шытсу авылында улы Мөдәрис һәм килене Гөлнур тәрбиясендә яши Рәхимә апа.

| Ф.И.О. | Туган елы | Туган урыны | Дәүләт бүләкләре | Бүләкләнгән вакытта эшләгән урыны | Үлгән елы | Күмелгән урыны |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 5 | 7 | 9 | 10 |
| **Абдрахманова Бибигәмбәр Фәррәх кызы** | 12.12. 1924 | Тат.АССР Саба районы Югары Шытсу авылы | «60 ЛЕТ ПОБЕДЫ В ВЕЛИКОЙ ОТЕЧЕСТВЕННОЙ ВОЙНЕ 1941-1945 гг.» | "1 Май" колхозы, колхозчы | 15.11. 2013 | ТР Саба районы Югары Шытсу авылы |
|  **Абдуллин Вәлиулла Абдулла улы** | 06.01. 1929 | Тат.АССР Саба районы Югары Шытсу авылы | «За доблестный труд в период ВОВ 1941-1945 гг.» | "1 Май" колхозы, колхозчы | 16.12. 1994 | ТР Саба районы Югары Шытсу авылы |
|  **Әбүбәкиров Кәшиф Ибраһим улы** | 02.11. 1928 | Тат.АССР Саба районы Югары Шытсу авылы | «За доблестный труд в период ВОВ 1941-1945 гг.» | "1 Май" колхозы, колхозчы | 03.04. 2004 | ТР Саба районы Югары Шытсу авылы |
|  **Әбүзәрова - Зарипова Хәдичә Зариф кызы** | 07.03. 1911 | Тат.АССР Саба районы Елыш авылы | «За доблестный труд в период ВОВ 1941-1945 гг.» | «Кызыл көч» колхозы, колхозчы | 07.03. 1985 | ТР Саба районы Елыш авылы |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| **Әһлиуллина Зәйнәп Әһлиулла кызы** | 05.01. 1909 | Тат.АССР Саба районы Елыш авылы | «За доблестный труд в период ВОВ 1941-1945 гг.» | «Кызыл көч» колхозы, колхозчы | 04.07. 1989 | ТР Саба районы Елыш авылы |
|  **Әдһәмов Мусабир Әдһәм улы** | 03.03. 1926 | Тат.АССР Саба районы Түбән Шытсу авылы | «ТРИДЦАТЬ ЛЕТ ПОБЕДЫ В ВЕЛИКОЙ ОТЕЧЕСТВЕННОЙ ВОЙНЕ 1941-1945 гг.» "60 ЛЕТ Вооруженных Сил СССР" "50 ЛЕТ Вооруженных Сил СССР" "За Победу над Японией" "За Победу над Германией в ВОВ 1941-1945 гг." "30 ЛЕТ Советской Армии и Флота" | "1 Май" колхозы, колхозчы | 20.08. 1984 | ТР Саба районы Түбән Шытсу авылы |
